| СОВЕТ БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2026 елның 26 августы** Бишнә авылы **№ 46**

Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче пенсия яшенә җиткән яисә муниципаль вазыйфаны биләгән чорда хезмәткә сәләтен югалткан һәм үз вәкаләтләрен туктаткан (шул исәптән вакытыннан алда) затларга бер мәртәбә акчалата бүләкләү түләү тәртибе турындагы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының 2026 елның 15 маендагы 36 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, юридик-техник хатаны бетерү максатыннан Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының 2026 елның 15 маендагы 36 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче пенсия яшенә җиткән яисә муниципаль вазыйфаны биләгән чорда хезмәткә сәләтен югалткан һәм үз вәкаләтләрен туктаткан (шул исәптән вакытыннан алда) затларга бер мәртәбә акчалата бүләкләү түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктта «әлеге Федераль законның» сүзләрен «Федераль законның» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 йорт

(Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Мәктәп урамы, 10 йорт (Бишнә мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**Бишнә авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**